**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**№ 14 Димтамак авылы 14 декаберь 2020ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципал районы
Димтамак авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге «Җир салымы турында»гы 28 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ санлы Россия Федерациясе Салым кодексының II өлешендәге 387 бүлегенең 31 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге «Җир салымы турында»гы 28 санлы карарына (2015 елның 23 маендагы 15 санлы, 2015 елның 15 октябрендәге 7а санлы; 2019 елның 29 ноябрендәге 19 санлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Салым ташламалары» 3 маддәсендәге 2 бүлекнеңң 10 бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) Оешмалар:

торак төзелеше өчен, шәхси торак төзелеше өчен, даими (билгеләнмәгән вакытка) файдалануга, шәхси торак төзелеше өчен, даими (билгеләнмәгән вакытка) файдалануга рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре өлешендә;

торак төзелеше өчен бирелгән һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре өлешендә;

гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата(урман парклары, парклар, скверлар, шоссе, урамнар, тыкрыклар, юллар, автомобиль юллары, мәйданнар, күперләр, чишмәләр, су объектлары, су алу скважиналары, каптаж, үләт базлары, һәйкәлләр, балалар мәйданчыклары, спорт мәйданчыклары, спорт өчен, сабантуй үткәрү урыннары, контейнер мәйданчыклары, гомуми файдаланудагы башка җирләр)»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, муниципаль районның рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырылган: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында эләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 1 өлешендәге 5 маддәсенең 3 һәм 4 бүлекләре нигезендә 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Димтамак авыл җирлеге башлыгы Ж.Ә.Хоснетдинов